| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
| --- | --- |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

02.02.2021 № 89

Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районы территориясендә урнашкан кешеләр күпләп җыела торган объектлар (территорияләр) исемлеген раслау турында» 2015 елның 19 июнендәге 684 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Полиция тарафыннан мәҗбүри саклanырга тиешле кешеләр һәм объектлар (территорияләр) күпләп була торган урыннарның һәм объектларның (территорияләрнең) террорчылыкка каршы якланыуына таләпләрне һәм мондый урыннарның һәм объектларның (территорияләрнең) иминлеге паспортлары рәвешләрен раслау турында» 2015 елның 25 мартындагы 272 номерлы карары һәм Алабуга муниципаль районы җирле үзидарә органнарынына җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча шәһәр җирле үзидарә органнары вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турындагы килешү нигезендә

КАРАР БИРӘ:

1. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районы территориясендә урнашкан кешеләр күпләп җыела торган объектлар (территорияләр) исемлеген раслау турында» 2015 елның 19 июнендәге 684 номерлы карарына үзгәрешләр кертергә һәм кушымта нигезендә Алабуга муниципаль районы территориясендә урнашкан кешеләр күпләп җыела торган объектлар (территорияләр) исемлеген яңа редакциядә расларга.
2. «Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районы территориясендә урнашкан кешеләр күпләп җыела торган объектлар (территорияләр) исемлеген раслау турында» 2015 елның 19 июнендәге 684 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 15 июленедәге 618 номерлы карарын гамәлдән чыгарырга.
3. Әлеге карар массакүләм мәгълүмат чараларында басылып чыккан көннән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче Л.Ф. Нургаянов

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
“ 89 ” 02.02.2024 ел
карарына 1 нче кушымта

Алабуга муниципаль районы территориясендә урнашкан кешеләр күпләп җыела торган объектлар (территорияләр) исемлеге

| № | Объектның исеме (территориясе) | Урнашу урыны (адресы) |
|---|---|---|
| 1. | Шишкин буалары | Алабуга шәһәре, Яр буе ур. |
| 2. | Ленин мәйданы | Алабуга шәһәре, Казан ур. |
| 3. | Александровка паркы | Алабуга шәһәре, Городище ур. |
| 4. | Ял паркы | Алабуга шәһәре, Тынычлык ур., 4 Б |
| 5. | «Майдан» шәһәр тамаша үзәге | Алабуга шәһәре, Шишкин ур., 80 |
| 6. | Пионерлар паркы | Алабуга шәһәре, Разведчиклар ур. |
| 7. | «Чебурашка» паркы | . Алабуга, Нефтьчеләр пр., 26 |
| 8. | «Яшь төзүче » БСЛ | Алабуга районы, Танай урманы, 7км |
| 9. | «Радуга шифаханәсе» ЯАҖ | «Түбән Кама» МП территориясе |
| 10. | «Космос» ССҮ | Алабуга районы, Танай урманы 7 км |
| 11. | «Урман әкияте » БСЛ | Алабуга районы, Танай урманы |
| 12. | «Макдоналдс» тиз туклану рестораны | Алабуга шәһәре, Нефтьчеләр пр., 28 |
| 13. | «Городище» рестораны | Алабуга шәһәре, Тынычлык проспекты, 2г |
| 14. | «Манхеттен» күңел ачу комплексы | Алабуга шәһәре, Интернационал ур., 16 |
| 15. | «Алабуга» СҖТ МИЗ | Алабуга районы, махсус икътисадый зона территориясе, «Алабуга», Ш-2 ур., 4/1 корп. |
| 16. | «Йорт янында бакча» скверы | Алабуга шәһәре, Автомобильчеләр ур. |
| 17. | «Татар бистәсе» гаилә комплексы /«Гаилә мунчасы» | Алабуга шәһәре, Тукай ур., 27в й. |
| 18. | «Татар бистәсе» гаилә комплексы /«Гаилә мунчасы» | Алабуга шәһәре, Чапаев ур., 72а й. |